# Чишмә башы

## Өчиле төп гомуми белем мәктәбе

Октябрь, 2025

**1 октябрь – Өлкәннәр көне**

### *Өлкәннәр көне*

Килеп тора,китеп тора
Бутәннәр көне.
Күңелләргә иң якыны-
Өлкәннәр көне!
Бар көчләрен эш өченгә
Түккәннәр көне.
Хезмәттә танылу алган
Өлкәннәр көне.
Илдән зурлау,кадер-хөрмәт
Көткәннәр көне.
Ихтирамга лаек затлар-
Өлкәннәр көне.
Тормыш юлын матур итеп
Үткәннәр көне.
Тантаналы,истәлекле-
Өлкәннәр көне.

Фанавис Давлетбаев



**5 октябрь - Укытучылар көне**

### *Укытучым*

Һәр карашың - гыйлем нуры синең,
Һәр сүзеңдә синең изгелек.
Әнидер син, бәлки,
Без дә синең
Бәгыреңнән төштек өзелеп.
Тактадагы акбур белән язган
Һәрбер җөмлә безнең күңелдә.
Мең галимнән якты йолдыз булып
Балкыйсың син белем күгендә.
Галимнәр дә галим була алмый,
Шагыйрьләр дә шагыйрь түгел лә, -
Син утырткан гүзәл гөлчәчәкләр
Шытып чыкмый калса күңелдә.
Әнидер син, бәлки,
Без дә синең
Бәгыреңнән төштек өзелеп.
Укытучы булу -
Фәрештәләр
Язып бетерә алмас изгелек!

Рифат Сәлах.



### *Әби белән бабушка*

Ике карчык гөрләшәләр тышта,
Берсе — әби, берсе — бабушка,
Берсе — оек, берсе чулок тоткан,
Икесе дә оста бик эшкә.
Дуслар да бик: пирог пешкән көнне
Әбине дә дәшә бабушка,
Бәлеш пешкән көнне бабушканы
Дәшми калмый әби бәлешкә.
Белгән сүзен русча, белмәгәнен

Үз телендә әби сукалый,
Ә бабушка, аңлаган күк аны,
Башын селки, күзен кыскалый.

Әби көлсә, ул да көлгән була,
Белмәсә дә нигә көлгәнен,
Күгәрчен күк гөрли-гөрли шулай
Уздыралар бергә көннәрен.

(Б.Рәхмәт)

### *Укытучысыз кеше булмый*

Укытучысыз кеше булмый,
Ул - һава кебек кирәк.
Укытучың булмаганда
Тибүдән туктый йөрәк.

Фикерләүдән туктый башың,
Күзеңдә сүнә нурлар.
Тормышта туктап каласың,
Өзелә барыр юллар.

Укытучысыз яшәп булмый,
Теләгем сезгә шушы:
Максатка юл күрсәтердәй
Табылсын укытучы!

Раил Гатауллин.

# Укытучы – хөрмәткә лаек...

## Укытучым – илаһи зат!

Зәңгәр томаннар артыннан сизелер – сизелмәс кенә кояш нурлары ал нур булып сузыла. Шушы нәзек нурлар томаннарны, әйтерсең лә эретеп юкка чыгара. Җиһан яктырып, кояш нурларына күмелә. Җылылык, иркенлек, әйтеп-аңлатып бетермәслек рәхәтлек күңелне иркәли.

Кояш нурына тиң сез, Укытучым! Бала күңелендәге шик-шөһбәләрне таратып ак юл сызасыз.

Бу һөнәр ияләренең, өйгә кайткач та, күпме көч түгеп тырышуларын, укучыларының уңышларына –шатлануын, арттарак калучылары өчен борчылуларын аңлыйм мин.

Укытучыларымны яратам, хөрмәт итәм.

Еллар узган саен, аларның маңгайларындагы тирән буразналар арта, күз төпләрендә җыерчыклар арта. Олыгайса да безнең күңелләрдә яшь булып калучылар алар...

Сабирова Азалия

Укытучы! Кем генә бу исемне зур хөрмәт белән телгә алмый икән? Һәркайсыбызның иң матур хәтирәләре, шатлык-борчулары, беренче дулкынланулары нәкъ менә мәктәп һәм укытучы белән бәйле. Беренче тапкыр мәктәп бусагасын атлап кергән көннән алып, бала белән янәшәдә аның укытучысы атлый. Бүген галим дә, ташчы да , иген үстерүче дә аның олы исеме алдында баш ия, чөнки теләсә нинди һөнәргә юл башы укытучының фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә салына . Ул дөньядагы барлык матур сыйфатларны үзенә туплаган. Киң күңеллелек, тырышлык, балаларга чиксез мәхәббәт, намуслылык… Андагы сабырлык- аналар сабырлыгына тиң.

Уйлап карасаң , укытучы булу җиңел түгел! Минем уйлавымча, чын мөгаллим булыр өчен гомер буе укырга, өйрәнергә, иң мөһиме балаларны яратырга һәм хөрмәт итә белергә кирәктер, мөгаен.

Минһаҗева Илүзә

# ОКТЯБРЬ...

Октябрь – көзнең икенче ае. Халык телендә бу мизгел «кара көз» дип йөртелә. Табигать инде җәйге яшеллеген җуйган, игеннәр җыелып, тунга сөрелгән басулар да каралып ята, урам-юллар пычрак, баткак...

Октябрь аенда агачлар төрле буяулар белән бизәлеп, яфраклар ташлый башлый. Көннәр кыскара, һавада салкын исе килә. «Октябрь аенда төшкә кадәр көз, ә төштән соң кыш», - дип юкка гына әйтмиләр.

Җылы октябрь-салкын кышка.
Көчле һәм дәвамлы салкыннар - кышкы салкыннарга.
Октябрь аенда салкыннар нинди көннәрдә башланса, киләсе елның апрелендә шундый ук көннәрдән җылыта башлаячак.
Октябрь аенда кайсы саннардан кар явачак, шул саннардан апрель аенда яз башланачак.
Беренче кар чын кышга кадәр кырык көн кала төшә.

Яфраклар тиз коелса -кыш суык булачак, ә яфраклар яшел булып калса һәм агачларда озак саклanса - кыш кыска була.